**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**10 октябрь 2019 ел** **№ 244**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хаты турындагы нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының социаль-икътисадый, интеллектуаль һәм мәдәни үсешенә зур өлеш керткән, хезмәттә, укуда аеруча зур уңышларга ирешүче гражданнарны һәм хезмәт коллективларын, дәүләт һәм һөнәри бәйрәмнәр, әһәмиятле һәм истәлекле даталар белән бәйле рәвештә бүләкләү максатыннан, Нурлат муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хаты турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы рәисе А.С. Әхмәтшин

Нурлат муниципаль район
Советының 2019 елның 10
октябрендәге 244 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башлыгының
Рәхмәт хаты турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Рәхмәт хаты икътисад, сәнәгать, фән, мәдәният, сәнгать, мәгариф, авыл хуҗалыгы, сәламәтлек саклау, спорт, дәүләтчелек, җирле үзидарә үсешенә керткән аерым шәхси өлеше, законлылыкны, хокук тәртибен, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен яклау эшендәге уңышлары (казанышлары), район һәм шәһәр халкы алдында башка казанышлар өчен бүләкләү формасы булып тора.

1.2. Рәхмәт хаты белән бүләкләү Нурлат муниципаль районы башлыгы карары белән рәсмиләштерелә.

1.3. Нурлат муниципаль районы башлыгы үз инициативасы белән гражданнарның яисә оешмаларның коллективларын, шулай ук җирле үзидарә органнары, район оешмалары, предприятиеләре, учреждениеләре, шул исәптән юридик затлар оештырмыйча гына иҗтимагый берләшмә җитәкчеләре үтенече буенча да, Рәхмәт хаты белән бүләкләргә хокуклы.

1.4. Гражданнарның шәхси мөрәҗәгатьләре буенча Рәхмәт хаты белән бүләкләү башкарылмый.

1.5. Бүләкләү өчен кирәк булган эш стажы әлеге оешмада, предприятиедә яки учреждениедә кимендә 1 елдан да ким булырга тиеш түгел (аерым очракларда күрсәтелгән сроклардан кимрәк)

## 2. Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында документлар тапшыру тәртибе

2.1. Рәхмәт хаты белән бүләкләү турындагы документлар Нурлат муниципаль районы башлыгы исеменә җибәрелә, үз эченә вазыйфаи затларны һәм оешмаларны Рәхмәт хаты белән бүләкләү турындагы үтенечнамәне һәм күрсәтмәне ала, оешма җитәкчесе тарафыннан имзалана һәм мөһер белән таныклана. (1нче кушымта).

2.2. Нурлат муниципаль районы башлыгы исеменә Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында документлар бүләкләү датасына кадәр 10 көн алдан карау өчен җибәрелә.

2.3. Нурлат муниципаль районы Советы Аппараты тәкъдим иткән затлардан бүләкләү турындагы үтенечнамәне карау барышында кандидат турында өстәмә белешмәләр соратып алырга хокуклы.

2.4. Бүләкләнүченең хезмәт кенәгәсенә аны Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында язма кертелә.

2.5. Нурлат муниципаль районы алдындагы яңа казанышлары өчен кабат рәхмәт хаты белән бүләкләү моннан алдагы бүләкләү тантанасыннан соң 1 елдан да

иртәрәк булмаса яки Нурлат муниципаль районы һәм аның халкы файдасына, шулай ук район Башлыгы инициативасы белән башкарылган аерым казанышлары өчен тапшырылырга мөмкин.

## 3. Рәхмәт хаты белән бүләкләү өчен документларны әзерләү, исәпкә алу һәм саклау тәртибе

3.1. Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында карар ике дәүләт телендә рәсмиләштерелә.

3.2. Рәхмәт хатын исәпкә алу һәм теркәүне Нурлат муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башкара.

## 4. Рәхмәт хаты тапшыру тәртибе

4.1. Рәхмәт хаты тантаналы шартларда Нурлат муниципаль районы башлыгы яки аның вәкаләтле вәкиле тарафыннан бүләкләнүче коллективка яисә шәхсән бүләкләнүче вазыйфаи затка тантаналы шартларда тапшырыла.

4.2. Рәхмәт хаты Нурлат муниципаль районы башлыгының бүләкләү турындагы карары чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча тапшырылырга тиеш.

4.3. Рәхмәт хаты югалган очракта дубликат бирелми.

4.4.Бүләкләнүче вафат булган очракта, аңа исән чагында тапшырылып өлгермәгән Рәхмәт хаты мәрхүм бүләкләнүченең гаиләсенә тапшырыла.

.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башлыгының Рәхмәт хаты турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында тәкъдим

1.ФИАи_______________________________________________________________

2. Вазыйфа, эш урыны ____________________________________________

_____________________________________________________________________

(предприятие, учреждение, оешманың төгәл исеме)

3. Туган көне _______________________________________________

(көн, ай, ел)

4. Коллективның яки бүләкләүгә тәкъдим ителә торган затның казанышлары һәм уңышлары төгәл күрсәтелгән кыскача характеристикасы

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

5. Булган бүләкләр (предприятие, тармак, район дәрәҗәсендә)_______________________________________________

_____________________________________________________________________

6. Тәкъдим ителгән бүләкләү формулировкасы (Рәхмәт хаты тексты)_________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

7.Кандидатураны тәкъдим итүче

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

(предприятие, учреждение, оешма җитәкчесе, хезмәт коллективы җыелышы)

____________________ "___" ______________ 20__ ел

(Ф.И.А.и, имза)